# ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АРЧА РАЙОНЫ ТЕРРИТОРИАЛЬ САЙЛАУ КОМИССИЯСЕ

# К А Р А Р

| 20.11.2017 | | №91 |
|---|---|---|

Татарстан Республикасы Арча муниципаль районының Урта Аты авыл җирлеге территориясендә 2017 елның 19 ноябрендәге җирле референдум нәтиҗәләре турында

«Россия Федерациясе гражданнарының сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» Федераль законның 70 статьясы, «җирле референдум турында» Татарстан Республикасы Законының 56 статьясы нигезендә, участок комиссияләренең тавыш бирү нәтиҗәләре турында участок комиссияләренең беренче нөсхәләре мәгълүматлары нигезендә, Татарстан Республикасы Арча муниципаль районының территориаль сайлау комиссиясе 2017 елның 20 ноябрендә узган җирле референдум нәтиҗәләре турында беркетмә төзегән, аның нигезендә, 2017 елның 19 ноябрендә узган җирле референдум нәтиҗәләре турында беркетмә төзеде:

Референдумда катнашучылар исемлегенә тавыш бирү тәмамлануга 818 референдумда катнашучы кертелгән, тавыш бирүдә катнашкан референдумда катнашучылар саны-709, бу муниципаль берәмлек территориясендә референдумда катнашучылар исемлегенә кертелгән референдумда катнашучыларның 86,67% ын тәшкил итә.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча референдумда катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

«Әйе» позициясе өчен референдумда катнашкан 620 (87,45%) кеше тавыш бирде, бу тавыш бирүдә катнашкан референдумда катнашучыларның 50 процентттан артыгын тәшкил итә; «Юк» позициясе өчен референдумда катнашкан 89 кеше тавыш бирде, бу 12,55% тәшкил итә.

Бәян ителгәннәр нигезендә Татарстан Республикасы Арча муниципаль районының территориаль сайлау комиссиясе карар кылды:

1. Татарстан Республикасы Арча муниципаль районының Урта Аты авыл җирлеге территориясендә 2017 елның 19 ноябрендәге җирле референдум узган, референдум нәтиҗәләре - гамәлдә дип танырга.

2 «Сез 2018 елда яшәү урыны буенча Арча муниципаль районы Урта Аты авыл җирлеге территориясендә теркәлгән һәр балигъ булган кешегә,түләү күләме 250 сум тәшкил иткән көндезге формада укучы студентлардан, 80яшьтән узган гражданнардан тыш, 500 сум күләмендә үзарасалым кертү һәм алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча түбәндәге эшләргә юнәлдерү белән килешәсезмее?

урам яктырткычлар алыштыру һәм урнаштыру; Тубән Аты ,Урта Сәрдә Кылачы авыллары

- каты көнкүреш калдыкларын вакытлыча туплау урыннарын тоту, трактор белән чүп-чарны тыгызлау: Тубән Аты ,Урта Сәрдә авыллары

-Кылачы авылы купере очен материаллар сатып алу һәм ремонлау.

җирлекнең торак пунктлары чикләрендә җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеге. Вак таш сатып алу, юл-урам челтәренә вак таш салу: Тубән Аты ,Урта Сәрдә ,Клачы авылларына

Аерым мәсьәләләр буенча экономия барлыкка килгән очракта акчаны Урта Аты авыл җирлеге "Башкарма комитетына референдумда билгеләнгән башка мәсьәләләрне хәл итүгә җибәрергә рөхсәт итәргә" дигән мәсьәлә буенча карар кабул ителде дип танырга.

3. Җирле референдум нәтиҗәләрен «Арча хәбәрләре» газетасында бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Арча муниципаль районының рәсми сайтында Интернет-телекоммуникация челтәрендә урнаштырырга.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары Регистрына кертү өчен Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Урта Аты авыл җирлеге башлыгына җибәрергә.

Татарстан Республикасы Арча районы
территориаль сайлау комиссиясе рәисе Б. И. Кадыйров

Татарстан Республикасы Арча районы
территориаль сайлау комиссиясе секретаре Л. И. Нурмиева